وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә
Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз!
Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп,
төрле юлларга китмәгез!

# ДИН вә МӘГЫЙШӘТ

№5 (122). 3 февраль 2012 / 11-раббигыль-әүвәл-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Мөселман яшьләренең II Проектлар бәйгесе башланды

▷2◁



Ике төрле стандартлар

▷3◁



Мәүлид бәйрәмен үткәрү гөнаһмы?

▷4◁

## ТАРИХИ ИСЛАМ



Без күпмилләтле дәүләттә яшибез, шуңа да милли һәм дини сорауларга игътибар итү бик тә мөһим. Илебездә булып үткән соңгы вакыйгалар бу мәсьәләләрнең бүгенге көндә дә актуаль булуын күрсәтә. РФ Премьер-министры Владимир Путин бу темага үзенең мәкаләсендә тикмәгә генә кагылмады. Милли сорауларны һичшиксез хәл итәргә кирәк. Ләкин аның чишелеше бары тик ниндидер яңа институтлар барлыкка килү белән генә чикләнеп калмасын иде. Андый төр институтлар ачылса да, алар аерым төбәк, милләт яки дин өчен генә түгел, ә барлык милләт вәкилләре өчен дә терәк булып торсын иде. Шуны ассызыклап үтәсем килә: әгәр дә дин мәсьәләләре турында сүз алып барсак, нәкъ менә ислам һәм православие диннәренең илебез өчен гадәти булган юнәлешләре аерым ярдәмгә мохтаж. Аларга чит илләрдән кергән идеологик басымга каршы тору өчен көч кирәк. Дәүләт ягыннан ярдәм бу очракта бигрәк тә яңа барлыкка килгән секталар белән көрәштә артык булмас иде. Илебез өчен гадәти булган диннәрнең өстенлекләре нәрсәдә соң? Эш шунда: без гасырлар буе бер-беребез белән бер илдә бердәм, дус мөнәсәбәтләрдә яшәп киләбез. Сәләфилеккә, бәлки, Согуд Гәрәбстанында кыйбла тотарга мөмкиндер, ләкин бездә мондый юнәлешнең булуы мөмкин түгел. Безнең юл - тарихи ислам. Хәнәфи мәзһәбе безнең җирлектә киң колач җәйгән, үз тамырларын җибәргән. Менә бу безнең өчен традицион юл була да инде. Туган җиребездә яңа барлыкка килгән калган юнәлешләр - миңа калса, илебезнең бердәмлеген, халыклар дуслыгын җимерүне максат итеп куючы, ялган, сәяси юнәлешләр.

Ватанга мәхәббәт исә ислам һәм православие диннәрендә хуплана, ә секталарда бу хакта сүз бөтенләй юк. Кайда гына булсак та, кая гына барсак та, безнең белән кем генә җитәкчелек итсә дә, без бу дөньяда бары тик кунаклар гына - шунысын онытмасак иде.

***Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ***

## ДӨНЬЯВИ МӘКТӘПТӘ - ДИНИ ДӘРЕСЛӘР



**Соңгы елларда күпдинле һәм күпмилләтле Россия Федерациясе мәктәпләрендә дини дәресләрне укыту мәсьәләсе укытучыларны да, ата-аналарны һәм киң җәмәгатьчелекне дә җитди борчуга салган иде. Дөрестән дә, күпләр дәүләт карамагында булган мәктәпләрдә мәҗбүри дин дәресләрен укыту илебезнең төп законы - Конституцияне һәм "Мәгариф турында"гы канунны төптән үзгәртү яисә турыдан-туры бозу, дөньяви мәктәпләрнең асылын үзгәртү белән тәңгәл китерерлек яман эш дип кабул итте.**

Әлбәттә, хәзер дә диннәр мәдәниятен һәм дин дәресләрен дөньяви мәктәпләрдә өйрәнү хакында бәхәсләр дәвам итә. Шулай булуга карамастан, рәсми карар кабул ителгәнлектән, мәктәпләр өчен бәхәсләргә нокта куелды. Быелның 1 апреленнән, ягъни уку елының IV чирегендә, республикабызның барлык мәктәпләрендәге IV сыйныф укучылары дини мәдәният яисә дөньяви этика нигезләрен өйрәнә башлаячак. Башлангыч мәктәп укытучылары өчен генә түгел, тулаем республика мәгариф системасы өчен дә мондый үзгә яңалыкны тормышка ашыру алдыннан бу эшне башлап йөрүчеләргә, ислам һәм христиан диннәре проблемалары белән шактыйдан ук шөгыльләнгән тарихчы буларак, үземнең кайбер фикерләремне җиткермәкче булам.

Белгәнебезчә, мәктәпләрдә "Дини мәдәният нигезләре һәм дөньяви этика" предметын өйрәнү Россиядәге традицион диннәрнең (православие, ислам, будда, яһүд) лидерларының 2009 елның җәендә Россия Президентына мөрәҗәгать итүеннән соң башланган иде. Шушы мөрәҗәгатьтән соң Президент Д.Медведев алар белән очрашты һәм үз карарын игълан итте. Шуның нигезендә "Дини мәдәният нигезләре һәм дөньяви этика" дәресләрен барлык мәктәпләрдә өйрәнә башлау алдыннан 240 мең укучыны һәм 10 мең мәктәпне үз эченә алган 19 төбәктә ике елга исәпләнгән эксперимент үткәрелде һәм ул уңай нәтиҗәләрен бирде.

Кызганыч, Татарстан әлеге чарада турыдан-туры катнашмады. Бу эксперимент Идел буе округыннан Чувашстан, Удмуртия республикаларында һәм Пенза өлкәсендә сынау узды.

***(Дәвамы 3 нче биттә.)***

## МӘҮЛИД АЕ

**Пәйгамбәребезнең (сгв) туган көне халкыбызда яратып үткәрелә. Мөхәммәднең вафат көне (Раббигыль-әүвәл аеның 12 нче көне) - аның туган көне буларак та олылап искә алына. Шуны да әйтеп үтәргә кирәк: Исламда туган көн бик тыйнак үткәрелә яки бөтенләй үткәрелми. Соңгы вакытта бу - бездә дә бик зур бәйрәм итеп үткәрелә башлады. Мәүлид аеның иң тантаналы көне - уникесендә.**

Мәүлид кичәсе - бик күңелле, күркәм тантана. Ул бер генә көндә үткәрелми, ә тоташ ай буе дәвам итә. Раббигыль-әүвәл ае - Мәүлид ае. Димәк, тантана бу айның беренче көненнән башлана. Менә шул Мәүлид ае башлангач, кешеләр үзләре теләгәнчә, хәленнән килгәнчә туганнарын, якыннарын, якын-тирәдәге карт-корыны, яшь-җилкенчәкне табынга җыя. Мәүлид ае ахырынача шулай бер-берсенә кунакка йөреп, Мәүлид укыйлар. Җомга көннәрне исә пәйгамбәребез Мөхәммәдкә (сгв) атап вәгазь сөйлиләр. Мәүлид кичендә мәчетләрдә пәйгамбәребез (сгв) хөрмәтенә Коръәннән сүрәләр укыла, вәгазь сөйләп, тантаналы гыйбадәт кылына, сәдака өләшенә. Мәүлид кичендә нинди дини йолалар үткәрү шарт? Бу гади генә кунак җыю түгел. Чакырылучылар арасында дини догалар укый белгән берәү булырга тиеш. Алар күп булса тагын да яхшырак. Табын өстәле янына җыелып беткәч (әлбәттә, барысы да тәһарәтле, хатын кызлар яулыктан, ир-атлар түбәтәйдән булырга тиеш), диндар кеше догадан "Мәүлидин-нәби" касыйдәсен (мактап язган шигырьләр) укый башлый. Пәйгамбәребез тормышында булган могҗизалар, кызыклы вакыйгалар турында сөйләнә. Урыны-урыны белән башлап укучы: "Салават" әйтик дигәч, табында утыручылар барысы да хор белән "Салават" әйтәләр. "Салават" әйтелеп беткәч, табын догаларын укыйлар һәм ашап-эчеп алалар. Бәйрәм ахырында хуҗаның теләге булса, хәер-сәдака таратыла, әмма ул мәҗбүри түгел. Чөнки табын сые үзе үк олы сәдака итеп исәпләнә. Иң ахыргы Пәйгамбәребезгә (сгв) атап дога кылына һәм Коръән укыла, мөнәҗәтләр әйтелә.

Мәүлид мәҗлесләрендә Коръәннең "Әхзаб (Гаскәрләр)" сүрәсеннән 38-48 нче аятьләрне ("Мәкәнә") уку бик саваплы.

***(Ахыры 2 нче биттә.)***

### ЯҢАЛЫКЛАР

**"КАЗАН МӨФТИЯТЕ" ИМАМНАРЫ БЕЛӘН ОЧРАШУ**

30 гыйнварда ТР мөселманнары Диния нәзарәте бинасында мөфти Илдус хәзрәт Фәиз "Казан мөфтияте" составындагы җирле дини оешмаларның имам-хатыйблары белән очрашты. Очрашуда Магадан шәһәре имам-хатыйбы Хәлим хәзрәт Шәмсетдинов, Киров өлкәсенең Малмыж шәһәре һәм Вятка аланы районындагы берничә авыл имам-хатыйблары катнашты.

Билгеле булганча, 2011 ел ахырында "Казан мөфтияте" мөселман дини оешмалары ассоциациясе гамәлдән чыгарылды. Сәбәбе - оешма уставында федераль кануннар белән төзәтеп булмаслык каршылыклар булуда. Әлеге оешма урынына яңасы - "Казан мөфтияте" мөселманнар Диния нәзарәте теркәлде. Мөфти Илдус хәзрәт Фәиз имамнарны республикада дин өлкәсендә башкарылучы эшләр белән таныштырды, Татарстан белән бергә эшләргә теләгән дини оешмалар белән хезмәттәшлекне дәвам иттерергә әзер булуын белдерде. Очрашу вакытында Илдус хәзрәт мамнарның күпсанлы сорауларына да җавап бирде.

**ХАЛКЫБЫЗГА ХЕЗМӘТ ӨЧЕН**

ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт Фәиз фәрманы нигезендә, Ульян өлкәсендә милләтебезнең гореф-гадәтләрен саклап калуга, мәдәниятен үстерүгә, ислам динен Идел буе мөселманнары арасында таратуга керткән өлеше өчен һәм 60 яшьлек юбилее уңаеннан Эдуард Әнвәр улы Ганиев "Халкыбызга хезмәте өчен" медале белән бүләкләнде.

**МӨФТИЯТТӘ – ИРАННЫҢ ГЕНЕРАЛЬ КОНСУЛЫ**

31 гыйнварда мөфти Илдус хәзрәт Фәиз Иран Ислам Республикасының Казандагы генераль консулы Рәсүл Шаян белән очрашты. Сүз дөньядагы ислам дине торышы һәм киләчәктә үзара хезмәттәшлек турында фикер алышу турында барды. Шулай ук генераль консул Коръән елында катнашырга теләк белдерде: "Сәнгать көзгесендә - Иран" шәмаилләр күргәзмәсен әлеге чаралар рәтенә кертергә тәкъдим ясады.

**"ЙӨРӘКТӘН - ЙӨРӘККӘ" АКЦИЯСЕ**

ТР мөселманнары Диния нәзарәте, "Европа+" радиосы белән берлектә, "Йөрәктән - йөрәккә" акциясен башлап җибәрде. Акция 2012 елның 1 февраленнән 1 мартына кадәр дәвам итәчәк.

Югары Ослангдагы картлар һәм инвалидлар интернат-йортына олылар өчен подгузниклар, урын-җир әйберләре, гигиена чаралары кирәк. Әлеге акция дә мохтаҗларның хәлләрен җиңеләйтү максатыннан, аларга ярдәм йөзеннән оештырыла.

Бүгенге көндә Югары Ослан интернат-йортында 85 инвалид бар, шуларның утыз өче - урын өстендә ятучы, даими игътибарга мохтаҗ картлар.

Ярдәм кулын сузарга теләүче барлык кешеләрне дә Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт (3 нче кат, 7 нче бүлмә) адресы буенча Диния нәзарәтенең хәйрия һәм ярдәм күрсәтү бүлегендә көтеп калабыз. Белешмәләр өчен телефон: 89872639889 (Гөлнара).

# МӘҮЛИД АЕ

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

Бисмилләһир-рахмәәнир-рахиим. Мәә кәәнә гәләәннәбиййии мин хәрәҗиң фиимәә фәрадалааһу ләһү сүннәтәллааһи фии-лләзиинә халәү миң каблү үә кәәнә әмру-ллааһи кадәрам макдүүраа. Әлләзиинә йүбәллигуунә рисәәлә-әти-лләәһи үә йәхъшәүнәһү үә ләә йәхшәүнә әхәдән илләллааһә үә кәфәә билләәһи хәсиибәә. Мәә кәәнә Мүхәммәдүнә әбәә әхәдиммирриҗ-әәликүм үә ләәкир-расүүлә-хатәмән-нәбиййи-ин. Йәә әййүһәә-лләзиинә әәмәнүз-күруллааһә зикраң кәсиираа. Үә сәббихүүһү бүкратәү-үә әсыйләә. Һүүәлләзии йүсаллии гәләйкүм үә мәләә'икәтүһүү лийүхриҗәкүм минә-ззулүмә-әти иләәннүүри үә кәәнә билмүьминиинә ра-хиимәә. Тәхиййәтүһүм йәүмә йәлкаунәһүү сәләәм. Үә әгәддә ләһүм әҗраң кәриимәә. Йәә әййүһәәннәбиййү иннәә әрсәлнәәкә шәәһидәүү үә мүбәшширау үә нәзииraa. Үә бәшширил-мүьминиинә би'әннә ләһүм минә-ллааһи фадләң кәбииraa. Үә ләә түтыйгил-кәәффири-инә үәл-мүнәәфик-ыйнә үә дәг әзәәһүм үәтәүәккәл гәләә-ллааһи үә кәфәә билләәһи үәкиилә.

Мәгънәсе (Ногмани тәфсиреннән): 38. Аллаһ пәйгамбәр галәйһиссәламгә фарыз, ваҗеб иткән нәрсәдә аңа тарлык кылмады, ягъни хатын алуда, Аллаһның гадәте синнән әүвәлге пәйгамбәрләргә дә хатын алуда тарлык кылмау иде. Аллаһы Тәгаләнең әмере хөкем ителмеш һәм үтәлмеш булды. 39. Синнән әүвәлге пәйгамбәрләр Аллаһның барча хөкемнәрен кавемнәренә ирештерер иделәр һәм һичкемнән курыкмыйча, фәкать Аллаһтан гына куркыр иделәр. Хисап итмәк вә хөкем кылмак өчен Аллаһ җитәдер. 40. Мөхәммәд галәйһиссәлам ирләрегезнең һәрберсенең атасы булмады, Зәеднең дә атасы түгел иде, хатынын алырга дөрестер, ләкин ул Аллаһның расүле вә пәйгамбәрләрнең ахыргысыдыр. Аллаһ һәрнәрсәне белеп эшләүче булды. 41. Ий мөэминнәр, Аллаһны күп зекер итегез. 42. Көннең әүвәлендә һәм ахырында Аны мактап тәсбих әйтегез. 43. Аллаһ вә Аның фәрештәләре сезгә рәхмәт итәләр, имансызлык караңгылыгыннан чыгып иман яктылыгына кертмәк өчен, ягъни Аллаһ Коръән белән иман яктылыгын вә һидәят юлын күрсәтер, фәрештәләр исә Коръән белән гамәл кылучы мөэминнәр өчен Аллаһтан ярдәм сорап дога кылырлар, Аллаһ Коръән белән гамәл кылучы мөэминнәргә рәхмәтле булды. 44. Хак мөэминнәргә Аллаһның бүләге сәламдер, терелеп кабердән кубарылган көндә ул сәламгә юлыгырлар. Вә аларга җәннәттә күркәм нигъмәтләр хәзерләдек. 45. Ий пәйгамбәр галәйһиссәлам, Без сине Ислам шәригатен кешеләргә ирештергәнлегеңә шаһит итеп, сиңа ияреп Коръән белән гамәл кылучы мөэминнәрне җәннәт белән шатландыручы, һәм Коръән белән гамәл кылмаучы кешеләрне җәһәннәм газабы белән куркытучы итеп җибәрдек. 46. Дәхи сине Аллаһның изене һәм әмере буенча кешеләрне Аллаһка иманга вә Ислам динен кабул итәргә өндәүче итеп, вә синең белән кешеләр туры юлны тапсыннар өчен сине белем яктылыгы белән җибәрдек.

47. Коръән белән гамәл кылучы мөэминнәрне шатландыр, Аллаһтан аларга олуг фазыл вә җәннәт нигъмәтләре булачагы белән! 48. Шәригать эшләрендә кяферләргә һәм монафикъларга итагать итмә, телләре белән сине рәнҗетүләрене куй, үч алма, һәр эшендә Аллаһка тәвәккәл ит, һәр эшендә сиңа вәкил булырга Аллаһ үзе җитәр.



## Яңа китап

***Дин әһелләренә дә, гади укучыларга да кулланма булырдай татарча дини китаплар даими чыгып тора. Мөбарәк Мәүлид ае уңаеннан "Иман" нәшриятында дөнья күргән "Мәүлед китабы" исемле яңа җыентык - шундый басмаларның берсе.***

Китапта Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) үрнәге, Мәүлидне үткәрү тәртибе, татарларда Мәүлид кебек темалар яктыртыла. Шулай ук басмага салаватлар, Мәүлидтә укыла торган аятьләр һәм Мәүлид догасы кертелгән.

116 битле китапның Мәүлид аенда күп мөселманнарга файдалы чыганак булуына ышанабыз, дип хәбәр итә **www.musulman.su сайты.**




# Гаяз Исхакый турында яңа китап дөнья күрде

**"Шәхесләребез" сериясенең чираттагы китабы - язучы, милләт лидеры Гаяз Исхакый турында. 27 гыйнварда китапның тәкъдим итү кичәсен Чистай якташлык җәмгыяте уздырды.**

Фәнни җыентык 927 битлек. Гаяз Исхакый турындагы хезмәт сигез бүлектән тора. Биредә әдипнең биографиясе, тәрҗемәи хәле, язучының Шиһабетдин Мәрҗани, Йосыф Акчура, Габдулла Тукай, Исмәгыйль Гаспралы кебек татар зыялылары турында язылган мәкаләләре урын алган. Китапка язучының мөһаҗирлеккә киткәч иҗат ителгән әсәрләре дә кертелгән. Шулай ук аның васыятьнамәсен укырга мөмкин.

Аерым бүлектә хатлары тупланган. Гаяз Исхакый, үзенең кызы Сәгадәткә, кызның әтисенә язган шәхси хатлары, Максим Горький белән хат аша аралашуларын укып була. Китапта шулай ук язучының фикердәше Муса Бигиевның хатлары урын алган. Бер бүлеккә архив материаллары тупланган. Китапка 147 документ кергән. Шулай ук китап авторлары Гаяз Исхакый турында басылган, чыккан хезмәтләренең биобиблиографиясен урнаштырганнар.




Саллы хезмәтне башкарып чыгаручы галимнәр - Сөләйман Рәхимов, Зөфәр Мөхәммәтшин, Айрат Заһидуллин.

Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галиме Зөфәр Мөхәммәтшин, Гаяз Исхакыйның чираттагы томнары редакцияләнеп, нәшриятка тапшырылырга әзерләнә, дип әйтте. Апрель аенда китапның берничә томы сатуга чыгарга тиеш, ди ул. 2013 елда әдипнең тууына 135 ел була. Кичәдә бу уңайдан аңа багышланган альбом чыгарырга кирәкле әйтелде.

Китап "туе"нда Татарстанның мәдәният министры Айрат Сибгатуллин, Татарстанның Казахстандагы элекке вәкаләтле вәкиле Илдус Тарханов, татар зыялылары, язучының якташлары бар иде. "Казан" милли-мәдәни үзәгендә узган кичәдә Чистайның Яуширмә авылындагы Г.Исхакый музеендагы кайбер экспонатлар да тәкъдим ителде. Камал театры артистлары Гаяз Исхакый әсәрләренә нигезләнеп язылган "Курчак туе" спектакленнән өзек тә күрсәтте.

**Римма БИКМӨХӘММӘТОВА**
**Чыганак: www.azatliq.org**

# Мөселман яшьләренең II Проектлар бәйгесе башланды

**Татарстанның Диния нәзарәте мөселман яшьләре өчен II Проектлар бәйгесе башлануын хәбәр итә. Бәйге 2012 елның 1 февраль көненнән башлап 1 июньгә кадәр дәвам итәчәк.**

Узган елның июль аенда исә Болгарда сәләтле мөселман яшьләренең "Алтын урта" I Проектлар мәктәбе үткән иде. Биредә Проектлар бәйгесендә катнашкан һәм иң уңышлы дип табылган эшләр катнашты.

Дүрт көн дәвамында мөселман яшьләре өчен төрледән-төрле мастер-класслар, тренинглар үткәрелде, алар проектларны дөрес итеп төзергә һәм аны тормышка ашырырга өйрәнде, аудитория алдында чыгыш ясады, лидерлык күнекмәләрен үзләштерде. Проектлар мәктәбенең соңгы көнендә мәртәбәле жюри әгъзалары каршына басып, һәр катнашучы үз проектын яклады. Нәтиҗәдә, биш җиңүче бүләкләнде, төрле номинацияләр билгеләнде һәм проектлар мәктәбенең җыентыгы басылып чыкты. Быел да Проектлар бәйгесе шул формада үтәр итәр дип көтелә. Чара мөселман яшьләрен берләштерү, аларның үсеш мөмкинлекләрен киңәйтү, мөселман яшьләренең үз ихтыяҗларыннан чыгып эшләнгән проектлары белән танышу, иң яхшы дип расланганнарын тормышка ашыру максатыннан оештырыла. Бәйгедә 30 яшькәчә булган һәркем катнаша ала. Катнашу өчен проект белән бергә гариза-анкетаны да тутырып җибәрергә кирәк.

Проектлар төрле юнәлештә булырга мөмкин. Мисал өчен, I Проектлар бәйгесенә "Төбәкара милли-мөселман лагере", "Мөселманнарның мәшгульлек үзәге", "Мәчетләрдә милли түгәрәкләр", "Шәҗәрә бәйрәме", "Мөселман хәрби частьләре" кебек эшләр тәкъдим ителгән иде.

Хатлар язу өчен адрес: 420111 Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең яшьләр бүлегенә.

ЭЛЕКТРОН АДРЕС: **dummol@inbox.ru.**

ЭЛЕМТӘ ӨЧЕН ТЕЛЕФОННАР: *+7* ***(843) 264 61 58 яки 89503146491 (Ләйсән).***



# ДӨНЬЯВИ МӘКТӘПТӘ – ДИНИ ДӘРЕСЛӘР

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

Шулай да мондый юнәлештәге эштән безнең республика да читтә калмады: кертеләчәк предметның концепциясен эшләүдә актив катнашты, Татарстан мәгариф һәм фән министрлыгында бу хакта галимнәр, укытучылар катнашында берничә мәртәбә саллы сөйләшүләр үтте, концепцияне камилләштерү, күпдинле аудиториядә эшләү юнәлешендә кулай ысуллар тәкъдим ителде.

Башлангыч мәктәпкә кертеләчәк "Дини мәдәният нигезләре һәм дөньяви этика" дип аталган комплекслы уку курсы алты аерым модульдән тора:

***1. Православие мәдәнияте нигезләре (Основы православной культуры).***

***2. Ислам мәдәнияте нигезләре (Основы исламской культуры).***

***3. Будда мәдәнияте нигезләре (Основы буддийской культуры).***

***4. Яһүд мәдәнияте нигезләре (Основы иудейской культуры).***

***5. Дөньякүләм дин мәдәниятләре нигезләре (Основы мировых религиозных культур).***

***6. Дөньяви этика нигезләре (Основы светской этики).***

Димәк, мәктәпләребездә һәр укучы тәкъдим ителгән алты модульнең берсен сайлап алырга һәм өйрәнергә тиеш. Республикабыз мәктәпләре өчен "Будда мәдәнияте нигезләре" чит булса, калган биш модуль актуаль булып кала, һәм без аларның берсен сайлап алып өйрәнергә тиеш.

IV сыйныфта яңа кертелә торган "Дини мәдәният нигезләре һәм дөньяви этика" предметы балаларны төрле диннәр тәгълиматын тирәнтен өйрәтүне максат итеп куймый. Бирелә сүз мәктәп укучыларын диннәр мәдәнияте нигезләре белән таныштыру, төрле диннәргә һәм милләтләргә толерант караш булдыру хакында гына бара. Әлеге дәресләр белән танышканнан соң балалар дөньядагы рухи кыйммәтләрнең нигезендә диннәр ятканлыгын аңларга, төрле милләтләрнең мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен бәяли белергә, аларны саклап калу кирәклегенә төшенергә, Россиядә яшәүче төрле халыкларның милли мәдәниятенә игътибарларын арттыруны күз алдында тота.

Диннәр мәдәниятенме, әллә бөтенләй дөньяви этика курсымы - болар барысы да укучылар теләгән, ата-аналарның караш-



мөнәсәбәтен, укытучы мөмкинлеген исәпкә алып сайланырга тиеш. Укучыларның, этиәниләрнең ихтыяҗын өйрәнгәннән соң, нинди модульне өйрәтү кирәклеген мәктәп мөстәкыйль төстә үзе хәл итә.

Төрле төбәкләрдә үткәрелгән эксперимент нәтиҗәләренә караганда, мәктәпләр төрле модульләр сайлап ала. Мисал өчен, Удмуртия Республикасында сайланган курслар түбәндәгечә: "Дөньяви этика нигезләре" - 48%, "Дөньякүләм дин мәдәниятләренең нигезләре" - 35%, "Православие мәдәнияте нигезләре" - 16,3%, "Ислам мәдәнияте нигезләре" - 0,7%.

Әлеге саннарга караганда, мәктәпләрдә сайланган иң күп курс - "Дөньяви этика нигезләре". Бер яктан караганда, бу - дөрес тә шикелле, тик "Дини мәдәниятләр нигезләре һәм дөньяви этика" предметының төп максатыннан чыгып фикер йөртсәк, мондый сайлауны бик үк кулай дип әйтеп булмый. Әлбәттә, барлык этик кагыйдәләрнең нигезендә дини нормалар ята. Тик шулай да мәктәптә турыдан-туры дини мәдәният нигезләрен өйрәнү отышлырак булыр иде. Чөнки республикабызда, башка төбәкләрдәге шикелле үк, православие һәм ислам мәдәнияте нигезләрен өйрәнергә ихтыяҗ зур һәм аны бүген булмаса, иртәгә канәгатьләндерергә туры киләчәк.

Хәзерге вакытта Татарстан мәгариф һәм фән министрлыгы мәктәпләрдә "Дөньяви этика нигезләре" һәм "Дөньякүләм дин мәдәниятләре нигезләре"н тәкъдим итә. Мәктәпләр, чыннан да, нәкъ менә шуларны сайлап алган. Рәсми мәгълүматларга караганда, республикабыз мәктәпләрендә "Дөньякүләм дин мәдәниятләре нигезләре"н - 20976, ә "Дөньяви этика нигезләре"н 13948 укучы өйрәнәчәк.

Республикабызда төрле диндәге халыклар, бер-берсе белән аралашып, бер-берсеннән үрнәк алып, дустанә эш йөртә. Мәктәпләрдә бер дин белән генә бәйләнгән дини дәресләрне укытуны башка диндә булган балалар да, ата-аналар да, укытучылар да аңламаячак. Бер сыйныфта төрле диндәге татар, рус, мари, чуваш, удмурт, яһүд һ.б. халыклардан булган балалар утыра һәм белем ала. Шуңа күрә классны дини яктан аермас өчен "Дөньяви этика нигезләре" яисә "Дөньякүләм дин мәдәниятләре нигезләре" модулен өйрәнү проблеманы уңай хәл итәргә мөмкинлек бирә.

Башка төбәкләр тәҗрибәсеннән чыгып караганда, мондый сайлау православие һәм ислам дине җитәкчеләрендә, кайбер ата-аналарда ризасызлык тудыра, һәм мәктәпләр аларның басымы астында Россиядә иң киң таралган православие һәм ислам дине мәдәниятен өйрәнүне башларга мәҗбүр була. Күршебез Пенза өлкәсендә нәкъ шундый хәл күзәтелгән. Эксперимент башланган 2010 елда бирегә барлык мәктәпләр диярлек "Дөньяви этика нигезләре"н сайлап алган, ә хәзер анда православие һәм ислам дине мәдәнияте нигезләрен шактый күп мәктәптә өйрәнәләр.

Мәктәпләрдә бу яңа предметны укытуның нәтиҗәсе тулаем укытучыдан тора. Бу яңа курсны кем укытырга тиеш соң? Мәктәп өчен дә, балалар өчен дә IV сыйныфта эшләгән төп укытучының әлеге дәресләрне алып баруы - иң кулае, минемчә. Тегеләй бу сәбәп аркасында башлангыч мәктәп укытучысы бу курсны укытырга ризалык бирмәсә, курсны башка укытучылар да алып бара ала. Мисал өчен, күршебез Удмуртия Республикасында укытучылар арасында 36% башлангыч мәктәбе укытучылары, 40 проценты - гуманитар фәннәр, 16 проценты - башка фән укытучылары. Пенза өлкәсе күрсәткечләре моңардан бераз аерылып тора. Бирелә дин дәресләрен 73% - башлангыч мәктәп укытучылары, 20% тарих һәм тел укытучылары укыта.

Республикабыз мәктәпләрендә ике курсны 2230 укытучы алып барырга тиеш. Шуларның мең алты йөз җитмеш өче - "Дөньякүләм дин мәдәниятләренең нигезләре"н, ә биш йөз илле җидесе "Дөньяви этика нигезләре"н укытырга тиеш. Дәресләрнең барысын да диярлек башлангыч сыйныф укытучылары алып барачак. Димәк, республикабыз бу өлкәдә үзенә генә хас юл сайлаган.

Хәзерге көндә башлангыч мәктәп укытучылары, мәгариф системасы бу предметны тулаем һәм аерым модульләре буенча дәресләр алып барырга тулысынча ук әзер түгел, чөнки бу предмет башлангыч мәктәп укытучыларын әзерләүче югары педагогик уку йортларында да, көллиятләрдә дә моңа кадәр укытылмады. Димәк, укытучыларны махсус курслар аша гына әзерләп булачак. Бу юнәлештә укытучылар өчен Мәгарифне үстерү институтында махсус курслар оештырыла. Кызганычка, әлеге курслар дистант рәвешендә, ягъни Интернетны файдаланып үткәрелгәнлектән, аның нәтиҗәсе хакында кистереп әйтеп булмый. Һәрхәлдә, яңа предмет буенча дәресләр башланыр алдыннан барлык укытучылар өчен методистлар, галимнәр, дин әһелләре катнашында саллы сөйләшүләр, очрашулар оештыру кирәклеге көн кебек ачык.

Республикабыз мәктәпләре өчен чишәсе тагын бер зур мәсьәлә - ул да булса курсларны ана телендә укыту. Руслар өчен бу проблема булмаса, татарлар өчен бирелә шактый эшлисе бар әле. Мәгариф һәм фән министрлыгы бу өлкәдә беркадәр эш башкарган инде. Мәскәүнең "Русское слово" нәшриятында нәшер ителгән А.Сахаров белән К.Кочегаровның "Основы религиозных культур народов России" дигән дәреслеге Татарстан мәктәпләре өчен махсус адаптацияләнгән, Россия ислам университеты ректоры Р.Мөхәммәтшин тарафыннан ислам диненә багышланган өлеше тулыландырылган. Бу дәреслек татарчага тәрҗемә ителде һәм мәктәпләргә таратылды. "Дөньяви этика нигезләре" дәресләге дә, бастырылып, вакытында мәктәпләргә килеп җитәргә тиеш. Шулай да, укытучылар өчен методик кулланмалар әлегә рус телендә генә әзерләнгән. Ислам мәдәнияте буенча дәреслек тә рус телендә. Республикабызда кирәшеннәр дә яшәгәнлеген истә тотарга кирәк, димәк, православие мәдәнияте нигезләрен дә бүген булмаса иртәгә татарчага тәрҗемә итәргә кирәк булачак.

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# ИКЕ ТӨРЛЕ СТАНДАРТЛАР

**Без бик еш Шәрык илләрен ике төрле стандартларны куллanулары өчен әрлибез. Ләкин, ни кызганыч, мөселманнар үзләре дә бу мәсьәләдә алардан ерак китмәгән.**

Берничә ел элек миңа диндәшләрем - Кавказ халыкларының берсендә кунакта булырга туры килде. Безнең арада кулларына тәсбих тотып, нәрсәдер турында уйланып, бер яктан икенче якка йөреп торучы бер карт бабай бар иде. Ул безнең бүлмәгә кергән саен, яшьләр олы кешене хөрмәт итү йөзеннән торып басалар иде. Фатир зур булмау сәбәпле карт безнең бүлмәгә минут саен керә иде. Һәм кич дәвамында карт кергән саен (!) яшьләр, тау халыкларындагы борынгы гореф-гадәт буенча, аны хөрмәтләп, урыннарыннан сикереп тора иде.

Картларга карата мондый хөрмәт миңа бик нык тәэсир итте. Ләкин бу хөрмәтнең башка милләт вәкилләренә дә таралмавы мине гаҗәпкә калдырды. Татар бабайлары кергәндә шул ук яшьләр тору түгел, хәтта аларга таба борылып та карамадылар. Шунда мин ике төрле стандартның мөселман илләрендә дә булуын беренче тапкыр күрдем: барлык өлкән кешеләрне дә түгел, ә үз милләтләре бабайларын гына хөрмәт итүче мөселманнар да бар икән.



Минем кардәшләр - сәләфиләр (ваһһабчылар) шулай ук ике төрле стандартларны кулланырга ярата. Гомумән, миңа сәләфиләрнең ораторлык осталыклары ошый: яхшы спектакльне караудан баш тартырга кыен шул. Сәләфиләр кебек югары дәрәҗәдәге оста актёрларны эзләсәң дә табарга читен. Аларның: "Аллаһы Тәгаләгә, Аның илчесенә һәм агагызда хакимлек итүчеләргә буйсыныгыз", - дигән Коръән аяте белән бизәлгән, ислам динендә хакимият темасына фәлсәфә сатулары гына алыйк. Сәләфиләр мөселман өммәтенең бердәм булуының әһәмиятен һәм үзебезнең хакимнәребезгә буйсыну кирәклеген ассызыклый. Ләкин чынлыкта "үзебезнекеләр" барысы да түгел, ә бары тик "үзләренеке" генә икәнлеге ачыклана. Шунда без сәләфиләрнең Коръән аятьләрен куллануларын бары тик оста актёрлар уены, спектакль икәнлеген аңлыйбыз.

Башка сәбәпләр белән сәләфиләрнең Татарстанда кулларыннан ычкынучы хакимиятне тотып калыр өчен, аңа ярсып (котырып) ябышуларын аңлатып булмый. "Арагызда хакимлек итүчеләр"гә буйсыну әһәмияте турындагы аятьне аларның Пәйгамбәребез (сгв) вакытлары түгел, ә үз хезмәт урыннары (минбәрләре) хакында сүз барганда кулланырга онытуларын ничек аңларга соң? Аларның төрле астыртын, мәкерле эшләр башкаруларына, халыкның аңын болгатуларына, судлашуларына, хатлар язуларына, "Ютуб"ка (www.youtube.com) видеороликлар төшереп җибәрүләренә күз салыйк. Аңга килегез! Әле кайчан гына безне ислам юлында берләшергә чакыручылар сез түгел идегезме? Безне экчерсезлеккә һәм югары дәрәҗәдәге хезмәт урыннарына утырырга омтылышның оят булуына өйрәтүчеләр сез түгел идегезме? Катгый рәвештә әмирләребезгә буйсынырга өндәүчеләр сез түгел идегезме? Шулай булгач, Татарстан мөселманнарының әмире - беренче чиратта, ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти. Димәк, Әбү Хәнифә сүзләре белән әйткәндә, сезнең имтихан тоту вакытларыгыз җитте, чөнки хәзер кем өчендер әмир "үзенеке түгел" була башлады.

Танылган татар дин эшлеклесе Муса хәзрәт Бигиев тормышыннан бер вакыйга искә төшә. Мөселманнар аның иҗатына төрлечә караштa булсалар да, аның танылган кеше булуы гына түгел, ә югары әхлаклы кеше булуы беркемдә дә шик тудырмый. Шейхел Ислам Муса әфәнденең китапларын тыйган фәтва чыгаргач, Истамбулда китап сатучы бер кеше, Муса әфәнденең китапларын үтемле булу сәбәпле, аңа чираттагы китапларын җибәрүен үтенеп хат яза.

Аңа Муса әфәнде болай дип җавап кайтара: "Әгәр дә Шейхел Ислам миңа каршы фәтва чыгарган икән, бу дөньяда аның фәтвасына буйсынучы беренче кеше мин булачакмын". Шулай итеп, Муса хәзрәт акчага бик мохтаҗ булса да, китап сатучының үтенечен кире кага.

Шейхел Исламга карата Муса хәзрәтнең дәгъвалары күп була, һәм ул үз дәгъваларын гадел (хаклы) дип исәпли. Ләкин аның өчен башкасы әһәмиятлерәк була - үзе тараткан фикерләргә чын күңелдән ышану. Ышану һәм шуннан тайпылмыйча яшәү.

***Рөстәм хәзрәт БАТЫР,***
***ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы рәисе***

# Мәүлид бәйрәмен үткәрү гөнаһмы?

**Бөтен галәмне юктан бар кылып тәрбия кылучы Аллаһы Тәгалә тарафыннан бәндәләргә ирештерелә торган хөкемнәрне гади генә булган һәрбер кеше саен ирештерү лаек та түгел һәм һәр кешенең бу хөкемнәрне кабул итәргә кабулияте дә, мөмкинлеге дә юк, чөнки ул Бөек затның хөкемнәрен ирештерүче фәрештә белән очрашырга, аның сүзләрен аңларга лаек булган зат кына моның кебек вазифага лаеклы булачагы да һәр акыл иясенә мәгълүм булса кирәк.**

Мәсәлән, надан кеше бөек дәрәҗәле галим кешедән аның фәнни, сәяси сүзләреннән вә хикмәтләрне аңлый да, төшенә дә алмавы һәм аны икенче берәүләргә җиренә җиткереп ирештерә алмаячагы көн кебек ачык аңлашыла. Галәмнәрне һәм анда булган җанлы һәм җансыз нәрсәләрне бар иткән, анда булган бөтен серхикмәтләрне, әүвәлен һәм соңгысын белүче Аллаһы Тәгалә белән гади бәндәнең арасы ничек буласы шуңа карап аңласын. Шуңа күрә дә Аллаһы Тәгалә үзенең камил хикмәте вә тәдбире буенча, бәндәләрнең үзләре арасыннан яхшы табигатьле, күркәм холыклы, пакь калебле, үзенең рәхмәт тәрбиясе белән тәрбияләнгән, һәм фәрештәгә юлыгырлык вә аннан сүз ишетерлек дәрәҗәгә ирешкән, аңардан Аллаһның сүзләрен өйрәнеп, аны аңлап халыкларга да аңлатырлык итеп ирештерергә лаек булган бер кадерле, хөрмәтле, инсафлы затны сайлап халыклар арасына илче итеп җибәрмештер. Менә шул илче Аллаһның кануннарын (динен) Аллаһы Тәгалә теләгәнчә, һичбер хыянәтсез итеп Аллаһны танытучы вә аңа гыйбәдәт кылу рәвешләрен өйрәтүче зат пәйгамбәр буладыр.

Менә шундый хөрмәтле булган пәйгамбәрләрнең иң соңгысы Мөхәммәд галәйһиссәләм ахырзаман пәйгамбәре, безнең пәйгамбәребездер. Шушы сәйидил мөрсәлин бөтен галәмгә рәхмәт өчен яратылган (вә мә әрсәлнә иллә рахмәтән лил галәмин) дип Аллаһы Тәгалә тарафыннан күп сыйфатлар белән макталган затның пәйгамбәрлеген танып иман китереп, мин синең өммәтеңнән дигән кешегә, рәсүлүллаһның нәсәб-шәрифен - Һашимгача 4 буынны белү важиб, ә Гаднәнгәчә белү мөстәхәб буладыр. Мөхәммәт ибне Габдуллаһ ибне Габделмоталлиб ибне Һашим ибне Габделманнаф.

"Бу Мәүлид бәйрәмен бәйрәм итү ярыймы, әллә бидгать эшме?" - дигән сүзләр халык арасында күп низаглар тудыра. Шуңа карата үзебез күргән китаплардан алып һәм махсус үз фикерләремнән дә йомгаклап ошбу хөкемне язарга булдым.

Рәсүлүллаһның туган көнен аерым билгеләп гаед (бәйрәм) итү әүвәлге IV-V гасырда булуы хакында ачык билгеле дәлилләр күренми. VI гасырда юмарт падишаһлардан булган Әрбәл падишасы Мөлек Мозаффар Әбү Сәгыйд Күкбүре ибне Гали ибне Биктәкин Рәсүлүллаһка (сгв) бик мәхәббәтле булганлыктан, шушы мәүлид кыйссасын олы аш-су хәзерләп, күп халыкны туйдырып сәдака кылуны чыгарган. Һәр елда Рәсүлүллаһның туган көнен хөрмәтләп, фәкыйрьләргә һәм гыйлем әһленә мал белән сәдака кылып ярдәм итә торган булган.

Мәүлид бәйрәмен исбатлый торган түбәндәге риваятьләр бар. Хафиз ибне Раҗәб үзенең "Ләтаифел мәгариф" дигән китабында, Мөслимнең Әбү Кутәдән риваять кылган бер хәдисне китерә. Рәсүлүллаһтан дүшәмбе көн ураза тотуның хикмәтен сораганда, ул әйткән: "Зәликә йәүмә вәлидтү вә уңзиләт галәййә фиһи нубувватә", ягъни: "Мин ул көндә тудым һәм миңа ул көндә пәйгамбәрлек килде", дигән.

Димәк, Рәсүл галәйһиссәләм үзенең туган көнен һәм пәйгамбәрлек килгән көнен тигез итеп аерым гыйбәдәт белән олуглап Аллаһ тарафыннан олуг нигъмәт дип танырлык, халыкларга да шөкранәсе тиешлекне аңлату өчен булса кирәк. Янә дә Хафиз Җәляледдин Әссөюти (рахимәһуллаһ) Мәүлид бәйрәмен имам Бәйһакый исбат вә тәхрөҗ иткән хадис шәрифтән дә аңлашыладыр. Хәдис: "Әнәс ибне Мәлик әйтә: "Рәсүлуллаһ (сгв) үзе өчен гакыйка кылды", - дип. Бәс, Рәсүлүллаһның бу гакыйкасы үзе тарафыннан тәшәккөр булса, өммәтенә дә шулай тәшәккөр юлын күрсәтер өчен була түгелме? Бу хакта төпченергә теләгәннәр шәйх Йосыф ибне Исмәгыйль Нәбһәнинең "Хөҗҗәтуллаһи галәл галәмин фи могҗизәти сәййидил мөрсәлин" дигән китабына карарга тәкъдим ителә.

Мәүлид бәйрәменең дөреслегендә безнең уебыз, югарыда сөйләнгәнчә ихлас күңелдән фәкать Аллаһ ризалыгы өчен изге ният белән, мәҗлес төзепме яки мәчетләрдәме, шушы сөекле пәйгамбәребезнең нәсел-нәсәбеннән алып та Кыямәт көнендә без гөнаһлы өммәтләренә шәфәгать кылыр өчен янган-көйгән минутларга кадәр булган хәлләрне гомум халыкка, бүген аның нинди зат булганын, ничек яшәгәнен, ни эшләр башкарганлыгын түгел, хәтта кайда, кайчан туганын да белә алмаган гафләттә булган халкыбызга ирештерү тиешледер.

Мисал. Депутат сайлаганда гына да ул син сайлый торган кешегә шәһадәт итеп тавыш биргәндә, аның кем икәнлеген белергә, аның тәрҗемәи хәлен белергә тиеш булгач, аның аркылы Аллаһның кануннарын кабул итә торган, Аллаһ белән без өммәтләре арасында вәсилә булачак һәм ул дәһшәтле Кыямәт көнендә аның шәфәгатен өмет итә торган кеше аның туган көнен искә алып, аңа салаватлар укып, аның белән таныш булмаганнарга танышу, аны оныттырмаска, икенче буыннарга да тапшырырга кирәктер.

Тик шул мәҗлесләрдә озак утырып вакыты кергән намазларның вакыты чыгып укымыйча калдырып, Аллаһның фарыз кылган олуг бурычын үтәмичә калдырып, каш ясыйм дип күз чыгарган кебек олуг гөнаһка дучар булмаска тиеш.

**Габделхак хәзрәт САМАТОВ**

# ДӨНЬЯВИ МӘКТӘПТӘ – ДИНИ ДӘРЕСЛӘР

***(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)***

Яңа курсны алып баручы мөгаллимәләр һәрдаим методик ярдәмгә мохтаҗ булачак. Шуңа күрә район мәгариф идарәләре, методик үзәкләр алар өчен махсус семинарлар үткәрергә, ә укытучылар методик әсбаплар белән тәэмин ителергә тиеш. Бигрәк аларга календарь-тематик план, дәрес эшкәртмәләре, һәр модуль буенча методик кулланмалар эшләргә туры киләчәк. Укытучыларның дин мәдәниятен укыту тәҗрибәсен, проблемаларны оператив чишү өчен һәр районда бу предмет буенча методик берләшмә оештырып, аның эшен җайга салу да кирәк булачак.

Бу эшне җайга салган вакытта республика мәгариф системасында тупланган тәҗрибәне дә файдалану кирәк, дип уйлыйм. Бу бигрәк тә "Ислам мәдәнияте нигезләре"н өйрәнгәндә кирәк булачак. Шактый күп еллар Балтач районында - "Әхлак дәресләре", ә кайбер районнарда "Диннәр тарихы" алып барылды. Күренекле дин галиме Р.Фәхреддиннең "Тәрбияле бала" һ.б. китапларын файдалану да кирәк.

Мәктәпләрдә "Дини мәдәният нигезләре һәм дөньяви этика" дигән комплекслы уку курсын укытуны оештырганда шуны истә тоту кирәктер: диннәрнең һәркайсы һәр кешене тумыштан ирекле итеп яратылуын таный. Кешене дингә көчләп яисә укытып кына ышандырып, инандырып булмый. Безнең җәмгыятьтә ирекле рәвештә генә һәр бала теге яисә бу динне яисә динсезлек юлын сайлап ала. Диннәр мәдәнияте турында һәр укучы, тиешле белемне башлангыч мәктәптә үзләштерә башлау белән бергә, дини тәрбияне гаиләдә ала алыр, дини уку чиркәүдә, мәчеттә, кирхада оештырылган очракта һәркем, балаларның вөҗдан ирекен бозмыйча, үз эшен алып барыр иде. "Дини мәдәният һәм дөньяви этика нигезләре" дәресләрен мәктәпкә кертү әлегә булмаган кискен проблемалар тудырып, тигез урында абынуга китерергә тиеш түгел. Шуңа күрә дини дәресләрне сайлауга бик җитди карарга кирәк.

Курс "Дини мәдәният нигезләре" дип аталса да, православие, ислам, яһүд, будда диннәре белән тирәнтен таныштыруны максат итеп куймый дип алда әйткән идек инде. Шулай да укытучылар тарафыннан артык тырышып динне идеологиягә әвереләдерү куркынычы саклана. Әйтергә кирәк, хәзерге заманда дингә, дини мәдәнияткә тормышта тиешле урын бирелсә дә, дини идеологиягә анда урын юк дәрәҗәсендә. Мәктәптә дини идеология дәресләрен бирә башласак, без төп Закон - Конституцияне бозар идек.

Соңгы вакытта мәгариф системасында туктаусыз яңалыклар кертелеп тора. Бу яңа курсларны үзләштерүне дә әлеге процессның бер чагылышы дип карарга кирәк. Мәгариф системасындагы бу катлаулы эшне җиренә җиткереп эшләрлек мөгаллимнәр булганда, балалар, ата-аналар өчен кирәкле һәм кызыклы курсны үзләштерү тиешле югарылыкта башкарылыр, дигән ышанычта калам.

**Фәйзелхак ИСЛАЕВ,**
**Мәгарифне үстерү институты профессоры,**
**тарих фәннәре докторы**

# Мәрхәмәтле булыйк!



***"Мәрхәмәтсезгә мәрхәмәт кылынмас..." (Хәдис)***

Адәм баласының тормышы шатлык-сөенечләрдән генә тормый. Кайвакыт ишек-тәрәзәләребезгә кайгы җиле дә кагылып уза. Бәла-казага очраган мөселман кая барырга, нишләргә тиеш соң?

Мөселман бәла-казага дучар булганда, иң беренче бу авырлыкны Аллаһ Раббыбыздан сынау дип белергә тиеш. Икенчедән, "Иннәхә лиЛләәһи үә инәә иләйһи раажигуун", ягъни: "Хакыйкатьтә, без - Аллаһтан, һәм Аның хозурына кайтачакбыз", дип, сабыр итәргә бурычлы.

Мөселман кешесенә килгән авырлыклар башка мөселманнар өчен дә сынау. Бу сынауда "яхшы" билге алу өчен, кардәшеңә килгән авырлыкны үзеңнеке кебек кабул итәргә кирәк. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) бик тә мәрхәмәтле кеше булган. Аның йомшак күңелле булуын тасвирлаучы кыйссалар шактый.

Бервакыт Рәсүлуллаһ (сгв) сәхабәләр белән сәфәрдә була. Сәхабәләр, үзләреннән ерак түгел генә кош оясы табып, "хуҗабикә"се кайтканчы кошның балаларын үзләренә алалар. Пәйгамбәребез (сгв) кошчыкларның әнкәсе кайтып, канат җилпеп, балалары янында очып йөргәнен күрә дә: "Кайсыгыз аның кошчыкларын алды? Кире кайтарыгыз үзенә!" - дип, сәхабәләргә мөрәҗәгать итә.

Икенче бервакытта Рәсүлуллаһ (сгв) яндырылган кырмыска оясын күрә дә: "Кем моны яндырды?" - дип сорый. Сәхабәләрдән берәү: "Мин!" - ди. Пәйгамбәребез (сгв) бу очракта да ачулана: "Беркем дә ут белән газапланмасын, бары тик утның Раббысы гына газаплар!" - ди.

Динебездә һәр җан иясенә карата мәрхәмәт каралган. Зыяны тимәгән бөҗәк яки кош-кортны үтерү, җәберләү дә золымга керә. Ә инде янәшәбездә яшәгән адәм балаларын, бигрәк тә мөселман кардәшләребез турында әйтеп тә торасы түгел.

Бәла аяк астында, диләр. Республикабызда, ЮХИДИ мәгълүматларына караганда, 2011 ел дәвамында 5566 юл-транспорт һәлакәте теркәлгән, 696 кеше һәлак булган, 7067 кеше җәрәхәтләнгән. Сәламәтлек саклау өлкәсендә Раббыбызның сынауларын шактый күрәбез: 2010 елда 18 яшьтән югары булучылар арасында 23830 инвалид теркәлгән.

"Зәкят" фондына мөрәҗәгать итүчеләр арасында тормышның авыр сынауларын - ачлык-ялангачлык, юл хәвефләре, "букет-букет" авырулар, ятимлек ачысын татучылар җитәрлек. Хөрмәтле мөселман кардәшләребез! Безнең арада яшәп, ярдәмебезгә мохтаҗ булучыларга битараф булмасак иде! Ә инде ярдәм кулын сузучыларга Аллаһ Раббыбыз җәннәт ишекләрен ача күрсен!

## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 4.02.2012 | 7:03 | 8:33 | 13:02 | 15:56 | 17:23 | 18:53 |
| Якшәмбе | 5.02.2012 | 7:01 | 8:31 | 13:02 | 15:57 | 17:25 | 18:55 |
| Дүшәмбе | 6.02.2012 | 6:59 | 8:29 | 13:02 | 15:59 | 17:27 | 18:57 |
| Сишәмбе | 7.02.2012 | 6:57 | 8:27 | 13:02 | 16:00 | 17:29 | 18:59 |
| Чәршәмбе | 8.02.2012 | 6:55 | 8:25 | 13:02 | 16:01 | 17:31 | 19:01 |
| Пәнҗешәмбе | 9.02.2012 | 6:53 | 8:23 | 13:02 | 16:03 | 17:34 | 19:04 |
| Җомга | 10.02.2012 | 6:51 | 8:21 | 13:02 | 16:05 | 17:36 | 19:06 |
| Шимбә | 11.02.2012 | 6:48 | 8:18 | 13:02 | 16:06 | 17:38 | 19:08 |

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №5 (122) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-524.

**Газета бушлай таратыла.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 2 февраль көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**